| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МЕНДЕЛЕЕВСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МЕНДЕЛЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК ШӘҺӘР<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2025 ел № 94

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Менделеевск шәһәр Советының
2024 елның 20 декабрендәге 85 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советы
КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2024 елның 20 декабрендәге 85 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 1 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында “103 786,80" санын «112 814,38558» санына алмаштырырга;

1 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында "0"санын»9027,58558" санына алмаштырырга.;

«2025 елга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Менделеевск шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары " 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

1.2. 4 статьяда:

«2025 елга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (эшчәнлекнең программага кертелмәгән юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» 3 нче кушымтада 1 нче таблицасын 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.;

«2025 елга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 4 нче кушымтада 1 нче таблицасын 3 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Норматив документлар»бүлегендә

урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск шәһәр Советының финанс-бюджет мәсьәләләре буенча даими комитетына йөкләргә.

Рәис урынбасары Н.Н.Сөләйманов